ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БОЛЬШЕМЕМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ОЛЫ МЕМИ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ


ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

с. Большие Меми

06.08.2018 11

«Олы Мәми авыл җирлеге территориясендә янгыннарны сүндерү көчләрен һәм чараларын җәлеп итү тәртибе турында»

“Янгын куркынычсызлыгы турында” 21994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Гадәттән тыш хәлләрне кисәтүнең һәм бетерүнең бердәм дәүләт системасы турында” 2003 елның 30 декабрендәге 794 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү буенча Россия Федерациясе Министрлыгы арасындагы килешүне раслау һәм бер-берсенә муниципаль һәм региональ характердагы гадәттән тыш хәлләрне, табигый бәла-казаларны сүндерүне һәм аларның нәтиҗәләрен кисәтүне оештыру мәсьәләләрен хәл итүдә үз вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыру турында” 2004 елның 15 октябрендәге 559номерлы карары, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 2005 елның 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2004 елның 10 ноябрендәге 480 номерлы «Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасының территориаль ярдәмче системасы турында» карары нигезендә,Олы Мәми авыл җирлеге территориясендә янгын сүндерүне оештыру максатларында

КАРАР БИРӘМ:

1. Янгын куркынычы зур булу сәбәпле, учак ягып җибәрүне, җирлек территориясендә чүп-чар яндыруны һәм Олы Мәми авыл җирлеге территориясендә урнашкан урманнарга автотранспортта керүне тыярга.
2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Олы Мәми авыл җирлеге территориясендә янгын сүндерү һәм авыл җирлеге характерындагы гадәттән тыш хәлләрне, табигый бәла-казаларны кисәтү һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү мәсьәләләрен хәл итү өчен янгын куркынычсызлыгы буенча мобиль төркем төзергә.
3. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Олы Мәми авыл җирлеге территориясендә янгын куркынычсызлыгы буенча мобиль төркем составын янгын сүндерүне оештыру һәм җирлек характерындагы гадәттән тыш

хәлләрне кисәтү, табигый бәла-казаларны бетерү мәсьәләләрен хәл итү өчен 1 нче кушымта нигезендә расларга.

4. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Олы Мәми авыл җирлеге территориясендә янгын куркынычсызлыгы буенча мобиль төркем составын янгыннарны сүндерү һәм җирлек характерындагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү, стихияле бәла-казалар һәм янгын сүндерү мәсьәләләрен хәл итү өчен кирәкле инвентарь белән тәэмин итәргә.

5. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Олы Мәми авыл җирлеге территориясендә янгыннарны, гадәттән тыш хәлләрне, табигый бәла-казаларны булдырмауга юнәлтелгән чаралар исемлеген 2 нче кушымта нигезендә расларга.

6. Югары Ослан муниципаль районы башкарма комитеты каршында янгын сүндерү гидрантлары, ранецлар сатып алуда, пирс белән җиһазландыруда катнашырга.

7. Янгын очрагында кешеләргә хәбәр итү өчен аваз сигнализациясе чараларының төзеклеген тикшерергә, шулай ук авыл җирлегенең торак пунктларында янгын сүндерү өчен өстәмә савытлар урнаштырырга.

8. Олы Мәми авыл җирлегендә хәвеф-хәтәр янау зонасында урнашкан торак пунктларны сөрү үткәрергә.

9. Карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

10. Карар аңа кул куйган вакыттан үз көченә керә.

.

Югары Ослан муниципаль районы Олы Меми авыл җирлеге башлыгы Г. А. Фомина

Югары Ослан муниципаль
районының Олы Мәми авыл
җирлеге Башкарма
комитетының2018 елның 6
августыннан № 11. Карарына
1 нче кушымта

Янгыннарны сүндерүне оештыру һәм җирлек характерындагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү, стихияле бәла-казаларны һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү мәсьәләләрен хәл итү өчен мобиль төркем составы

| №п\п | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Контакт телефоннары | Янгынны сүндерү өчен инвентарьлар белән тәэмин итү |
|---|---|---|---|
| Зур Мәми авылы | | | |
| 1. | Богаткин В.С. | 89872648364 | Көрәк, кирка |
| 2. | Фомин Д.С. | 89520369523 | мотопомпа |
| 3. | Дондуков Д.Е. | 36-0-44 | Мичкәле Т-40 |
| 4. | Баймяшкин Н.М. | 89600365933 | МТЗ - 82 |
| 5. | Картапов Н.М. | 89274429017 | водокачка |
| Заборная Поляна | | | |
| 1. | Галикбаров Р.Г. | 89179362643<br>36-0-06 | Мотопомпа, көрәк, кирка |
| 2. | Лихачев Н.М. | 89375297213 | Көрәк, кирка |

Югары Ослан муниципаль районы
Олы Меми авыл җирлеге башлыгы Г. А. Фомина

Югары Ослан муниципаль
районының Олы Мәми авыл
җирлеге Башкарма комитетының
2018 елның 6 августыннан 11
номерлы карарына
2 нче кушымта

Олы Мәми авыл җирлеге территориясендә янгыннарны, гадәттән тыш хәлләрне, табигый бәла-казаларны булдырмауга юнәлтелгән чаралар исемлеге.

| №п\п | Чаралар исеме | Җаваплы башкаручы | Элемтә өчен телефон номеры |
|---|---|---|---|
| 1 | Халыкны йөреп чыгу һәм янгын куркынычсызлыгы торышын тикшерү | Фомина Галина Александровна<br>Сальцинова Анна Александровна | 89520368823<br>89631242735 |
| 2 | Торак пунктларда коры-сары чабу | Фомина Галина Александровна | 89520368823 |
| 3 | Авыл халкы җыенын оештыру һәм аңлату эшләре алып бару | Фомина Галина Александровна | 89520368823 |

Югары Ослан муниципаль районы Олы Меми авыл җирлеге башлыгы Г. А. Фомина